**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 27 мартындагы 967 номерлы карары**

**Электр транспортында пассажирлар йөртүгә билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллануга бәйле алынмый калган керемнәрне каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2025 елның 17 декабрендәге 5-4 номерлы «2026 елга, 2027 һәм 2028 елларның план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карары, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 30 гыйнварындагы 266 номерлы «Электр транспортында пассажирлар йөртүгә билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллануга бәйле алынмый калган керемнәрне каплау максатыннан оешмаларга субсидия алучыларны раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә Электр транспортында пассажирлар йөртүгә билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллануга бәйле алынмый калган керемнәрне каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетын Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан электр транспортында пассажирлар йөртүгә билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллануга бәйле

алынмый калган керемнәрне каплау максатыннан оешмаларга субсидияләр бирү буенча Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы дип билгеләргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 17 мартындагы 745 номерлы «Электр транспортында пассажирлар йөртүгә билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллануга бәйле алынмый калган керемнәрне каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 27 мартындагы
967 номерлы карарына
кушымта

**Электр транспортында пассажирлар йөртүгә билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллануга бәйле алынмый калган керемнәрне каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип электр транспортында пассажирларны йөртү өчен билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллануга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү процедурасын билгели.

2. Субсидия бирүнең максаты булып электр транспортында пассажирлар йөртү өчен билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллануга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау тора.

3. Субсидияләр Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан Казан шәһәре Думасының тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатка субсидияләр бирү өчен бюджет чараларын алучы буларак Вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидия сайлап алу үткәрмичә бирелә.

5. Субсидия бирү ысулы – алынмый калган керемнәрне каплау.

Каплау өчен субсидия бирелә торган алынып бетмәгән керемнәргә әлеге Тәртипнең 24 пунктында билгеләнгән формула буенча исәпләнә торган көйләнә торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча җир өсте электр транспортында һәм метрополитенда пассажирлар йөртү буенча финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килүче чыгымнар һәм керемнәр арасындагы аерма керә.

6. Субсидияләр турында, шул исәптән бюджет турында карар (бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында карар) буенча каралганнары турында мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы (алга таба – «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләрен Вәкаләтле органга җиткергән көннән соң килә торган 10 эш көне эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

7. Субсидия алучылар Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 30 гыйнварындагы 266 номерлы «Электр транспортында пассажирлар йөртүгә билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллануга бәйле алынмый калган керемнәрне каплау максатыннан оешмаларга субсидия алучыларны раслау турында»гы карары белән билгеләнә.

8. Вәкаләтле органның Субсидия алучы белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

9. Субсидия алучының «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технология хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

10. Вәкаләтле орган «Электрон бюджет» системасында субсидия бирүгә килешү төзүгә гаризаларны (алга таба – гариза) кабул итү процедурасын рәсмиләштерә. Әлеге процедура үз эченә түбәндәге мәгълүматны ала: гаризаларны кабул итү вакытларын, гаризаларны тапшыра башлау һәм кабул итү тәгәлләнү көннәрен һәм вакытын, шул ук вакытта, гаризаларны кабул итү процедурасын урнаштырганнан соң, гаризаларны кабул итү тәгәлләнү көненә кадәр кимендә биш календарь көн калырга тиеш.

11. Вәкаләтле органга гариза бирү көненә Субсидия алучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

а) чит ил юридик заты, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав

(җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда, акцияләре Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашуы белән гамәлгә ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

б) экстремистик эшчәнлеккә яисә террорчылыкка катнашы барлыгы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә торырга тиеш түгел;

в) БМО Уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары нигезендә махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә торырга тиеш түгел;

г) әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максат өчен норматив хокукый актлар нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан, Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алучы булып тормый;

д) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк (юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый);

е) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы, шул исәптән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты алдында акчалата йөкләмәләр буенча түләү вакыты узган (җайга салынмаган) башка бурычы юк;

ж) аңа карата үзгәртеп кору (субсидия алучы юридик затка башка юридик затны кушу формасында үзгәртеп корудан тыш), бетерү процессы алып барылмый, банкротлык процедурасы кертелмәгән, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

з) дисквалификацияләнгән затлар реестрында юридик зат булып торган Субсидия алучының дисквалификацияләнгән җитәкчеләре, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яисә баш бухгалтеры (булган очракта) турында белешмәләр юк;

и) 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый.

Субсидия алучының әлеге пунктның таләпләренә туры килү-килмәвен карап тикшерү дәүләт мәгълүмат системалары мәгълүматлары нигезендә «Электрон бюджет» системасында, шул исәптән ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын кулланып (автоматик тикшерүнең техник мөмкинлеге булганда) автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә тикшерүне гамәлгә ашыру өчен техник мөмкинлек булмаган очракта, Субсидия алучының әлеге пункт таләпләренә туры килү-килмәвен раслау «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында тамгаларны Субсидия алучы тарафыннан электрон рәвештә билгеләп кую аша башкарыла.

Билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү өчен җаваплылыкны Субсидия алучы йөртә.

12. Субсидия алучы веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә гариза төзи һәм тапшыра һәм «Электрон бюджет» системасына түбәндәге документларның (сканерлап электрон формага үзгәртелгән кәгазьдәге документларның) электрон күчермәләрен тапшыра:

1) Казан шәһәренең шәһәр (муниципаль) трамвай, троллейбус маршрутлары һәм метрополитены буенча гомуми файдаланудагы шәһәр электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча муниципаль контрактларның (килешүләрнең) булуын раслый торган документ;

2) шәһәр пассажир транспортында йөргән өчен түләүнең автоматлаштырылган системасы операторы белән төзелгән килешү;

3) кертелгән барлык үзгәрешләрне исәпкә алып, гамәлгә кую документлары;

4) җитәкче вәкаләтләрен раслый торган документлар;

Гаризада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- Субсидия алучы турында мәгълүмат һәм документлар;

- Субсидия алучының тулы һәм кыскартылган атамасы;

- Субсидия алучының төп дәүләт теркәү номеры;

- салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры;

- салым органында исәпкә кую датасы һәм коды;

- юридик зат адресы;

- юридик яктан әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм электрон почта адресы;

- Субсидия алучының җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры, вазифасы);

- субсидия күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе әмере белән билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә субсидия бирүгә килешүне (алга таба – килешү) имзалауга вәкаләтле зат хакында мәгълүмат;

- Субсидия алучы турында, субсидия алучы тарафыннан бирелгән гариза, шулай ук Субсидия алучы турында субсидия бирү белән бәйле башка мәгълүматны «Интернет» челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык.

Вәкаләтле органга Субсидия алучының әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатыннан документлар һәм мәгълүмат бирүне, Вәкаләтле органның ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында файдалана алу мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булганда, Субсидия алучы бу документларны һәм мәгълүматны Вәкаләтле органга үз инициативасы белән тапшырырга әзер булган очрактан тыш, Субсидия алучыдан таләп итү тыела.

Гаризага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре документны тулысынча яисә аның фрагментын мәгълүмат карауның һәркем файдалана алырлык программа тәэминаты чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга һәм аларның эчтәлеге белән махсус программа яисә технологик чаралардан башка танышырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә якланган булырга тиеш түгел.

13. Гариза Субсидия алучы җитәкчесенең яки аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Россия Федерациясе законнары нигезендә гаризада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Субсидия алучы җаваплы була.

14. Субсидия алучы тарафыннан имзаланган гаризага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры куелган көн субсидия алучының гариза тапшыру датасы итеп дип санала.

15. Субсидия алучы тарафыннан эшләп бетерү өчен гаризаларны кайтару күздә тотылмый.

16. Вәкаләтле орган Субсидия алучының гаризасын алган көннән соң биш календарь көннән дә соңга калмыйча карап тикшерә.

17. Гаризаны кире кагу өчен нигезләр:

- Субсидия алучының әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- Субсидия алучы тарафыннан тапшырылган гариза һәм документларның әлеге тәртипнең 12 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

- Субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турында мәгълүматның дөрес булмавы;

- документларның тулы булмаган җыелмасын тапшыру.

18. Гариза таләпләргә туры килгәндә һәм гаризаны кире кагу өчен әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаганда, тиешенчә тутырылган дип таныла.

Гаризаның әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы карар Вәкаләтле орган тарафыннан Субсидия алучы гариза составында тапшырган мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләрен алу датасына кабул ителә.

19. Гаризаның әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турындагы карар имзаланган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган бер көн эчендә Вәкаләтле орган Субсидия алучыга килешү проектын җибәрә.

Субсидия алучы, өч эш көненнән дә соңга калмыйча, алынган килешүне имзаларга тиеш. Җибәрелгән килешү билгеләнгән вакытта имзаланмаган очракта, Субсидия алучы килешүне имзалаудан баш тарткан дип таныла һәм бу очракта субсидия бирелми.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ формасында төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокукы булган затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән имзалана.

20. Килешү түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

- бюджет чараларын алучы буларак төп бүлүчегә килешүдә билгеләнгән

күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү яки, яңа шартлар буенча килештерүгә ирешелмәгәндә, килешүне өзү турында;

- Субсидия алучының, Субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашкан җәмгыятьләрдән, устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашкан коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне тикшерүгә ризалыгы турында;

- югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлаучы эшләнмәләрне сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле әлеге Тәртип белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча хисабына Субсидия алучылар – юридик затлар, шулай ук Субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан чит ил валютасы алуны тыю турында.

Кирәк булган очракта, Вәкаләтле орган субсидия алучы белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Юридик зат булган субсидияне алучыны кушу, кушылу яки үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп оештырганда, килешүгә, хокуклар күчә торган юридик затны килешүдә күрсәтеп, килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән йөкләмәдә затны алмаштыру өлешендә үзгәрешләр кертелә.

Юридик зат булган субсидия алучыны бүлү, бүлеп чыгару рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук юридик зат булган субсидия алучы юкка чыгарылганда, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен тиешле бюджетка кире кайтару турында мәгълүматны күрсәтеп, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт формалаштырып, килешү өзелә.

21. Субсидия алучы субсидияләр алу өчен Вәкаләтле органга ай саен килешүдә билгеләнгән форма буенча түбәндәге документларны тапшыра:

1) субсидия алу өчен гариза (алга таба – гариза);

2) электр транспортында пассажирлар йөртүгә билгеләнгән җайга салына торган тарифны куллану турында хисап. Югарыда күрсәтелгән хисапны, шулай ук башка хисапларны бирү тәртибе, вакытлары һәм формалары субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнә;

3) Субсидия алучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты чыккан салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмавын (булмавын яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмавын) раслаучы, документлар тапшыру көненә кадәр 30 календарь көннән артмаган вакытта бирелгән документлар. Бурыч булган очракта, Субсидия алучы гариза бирү датасына кадәр әлеге бурычны тулысынча каплау турында түләү йөкләмәләренең күчермәләрен тапшырырга хокуклы.

Тапшырылган документларның күчермәләре Субсидия алучы тарафыннан расланырга һәм аларга мөһер (булган очракта) сугылырга тиеш.

Гариза Субсидия алучының җитәкчесе яки Субсидия алучы җитәкчесе вәкаләт биргән зат тарафыннан имзалана.

Әлеге пункт нигезендә Субсидия алучы тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә Субсидия алучы җаваплылык тота.

22. Субсидия алучы гаризасын тапшыру көне дип Вәкаләтле орган тарафыннан Субсидия алучының гаризасына теркәү номеры бирелгән көн санала.

23. Әлеге Тәртипнең 21 пунктында каралган гаризаны һәм документларны Субсидия алучыга эшләп бетерү өчен кире кайтару каралмаган.

24. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$РС = Р - Д,$$

әмма Вәкаләтле органга карата расланган бюджет ассигнованиеләреннән һәм бюджет йөкләмәләре лимитларыннан күбрәк түгел, биредә:

РС – субсидия күләме;

Р – даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның

муниципаль маршрутларында һәм метрополитенда пассажирлар йөртү буенча финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә торган икътисади яктан нигезләнгән чыгымнар, шул исәптән түбәндәгеләр өчен түләнгән чыгымнар:

- хезмәт өчен түләү;
- хезмәт хакын түләү өчен бүленгән иминият кертемнәре;
- электр энергиясе;
- техник хезмәт күрсәтү һәм хәрәкәтчән составны һәм инфраструктура объектларын ремонтлау;
- амортизация;
- гомумхуҗалык чыгымнары;
- социаль характердагы түләүләр;

Д – җир өсте электр транспорты һәм метрополитенның даими муниципаль маршрутларында пассажирларны йөртү буенча хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр, шул исәптән түбәндәгеләр өчен:

- билетлар сатудан килгән керем;
- исемле бердәм социаль юл билетларын (алга таба – ташламалы транспорт картасы) тулыландырудан кергән керем;
- җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән алынып бетмәгән керемнәрне каплауга субсидияләр.

25. Вәкаләтле орган гаризаны һәм әлеге Тәртипнең 21 пунктында каралган документларны гариза алган көннән соң ун эш көне эчендә карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яисә субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул итә. Субсидия бирү турындагы карар килешүдә билгеләнгән форма буенча рәсмиләштерелә.

26. Субсидия бирүне кире кагу өчен нигезләр:

- Субсидия алучы тарафыннан тапшырылган гариза һәм документларның әлеге Тәртипнең 21 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);
- Субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турында мәгълүматның дөрес булмавы;
- документларның тулы булмаган җыелмасын тапшыру;
- бюджет йөкләмәләре лимиты бетү.

27. Әлеге Тәртипнең 26 пункты нигезендә субсидия бирү кире кагылган очракта, Субсидия алучы субсидия бирү турында гариза һәм әлеге Тәртипнең 21 пунктында күрсәтелгән документлар белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

28. Субсидия әлеге Тәртипнең 21 пунктында күрсәтелгән, Субсидия алучы тарафыннан Вәкаләтле органга килешүдә билгеләнгән формалар буенча тапшырылган документлар нигезендә ай саен бирелә.

Тапшырылган документларның күчермәләре Субсидия алучы тарафыннан расланырга һәм аларга мөһер (булган очракта) сугылырга тиеш.

29. Вәкаләтле орган:

- субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Субсидия алучылар тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына үз шәхси счетыннан акчалар күчерә;

- агымдагы финанс елының декабрь аена субсидия агымдагы финанс елының 31 декабренә кадәр, агымдагы финанс елының ноябре өчен тиешле субвенцияләр күләмендә, әлеге Тәртипнең 34 пунктында күрсәтелгән, пассажирларны электр транспортында йөртү өчен билгеләнгән көйләнә торган тарифны куллану турында хисап буенча Вәкаләтле орган тарафыннан күчерелә.

Агымдагы финанс елының декабренә бирелгән субсидияләр оешмаларга шушы ай өчен тиешле субсидияләрдән артып киткән очракта, артып киткән сумма Вәкаләтле органга кайтарылырга тиеш.

Агымдагы финанс елының декабрь аена бирелгән субсидияләр оешмаларга күрсәтелгән чор өчен тиешле субсидияләрдән азрак булган очракта, җитеп бетмәгән сумма агымдагы елдан соң килүче елның 31 гыйнварына кадәр Вәкаләтле орган тарафыннан күчерелә.

30. Субсидия бирү нәтиҗәсе – әлеге Тәртипнең 31 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәлелек күрсәткеченең үтәлешен саклап, билгеләнгән көйләнә торган тарифлар буенча электр транспортында пассажирлар йөртүне тәэмин итү, аның күрсәткече кимендә 0,8 дип кабул ителә.

31. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткече булып пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда шәһәр (муниципаль) трамвай, троллейбус маршрутлары һәм Казан шәһәре метрополитены буенча гомуми файдаланудагы шәһәр электр транспортында транспорт хезмәте күрсәтүнең ышанычлылыгы тора, ул «пассажирларны һәм багажны даими ташу маршрутлары расписаниеләрен үтәү коэффициенты» күрсәткече ярдәмендә бәяләнә, аның зурлыгы > = 0,8 булырга тиеш.

Пассажирларны һәм багажны даими ташу маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты ($К_{расп}$) һәр төр транспорт (трамвай, троллейбус, метро) өчен түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К_{расп} = \frac{\sum Q_{фактрейс}}{\sum Q_{рейсрасп}} \geq 0,8$$

, биредә

$Q_{фактрейс}$ – пассажирлар һәм багаж ташу вакытында башкарылган фактик рейслар саны;

$Q_{рейсрасп}$ – расписание белән билгеләнгән пассажирлар һәм багаж ташу вакытында рейслар саны.

32. Субсидия алучы «Электрон бюджет» системасында субсидия бирү турында килешү белән билгеләнгән форма буенча квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча, нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында хисап, субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, еллык хисап тапшыра.

Вәкаләтле орган хисапларны кабул итә һәм Субсидия алучы тарафыннан хисаплар тапшырылган көннән алып биш эш көне эчендә аларны тикшерә.

33. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда, шул исәптән шартларның үтәлмәве Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерү фактлары буенча ачыкланган очракта, бирелгән субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән алып утыз эш көне эчендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

34. Акчаларны Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә үз теләге белән кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

35. Субсидияләр алучыларга – юридик затларга, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы башка юридик затларга, чит илдән югары технологияле җиһазлар, чимал һәм комплектлаучы эшләнмәләр сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле операцияләрдән, Тәртип белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, Россия Федерациясе бюджет

системасының тиешле бюджетыннан алынган акча хисабына чит ил валютасы сатып алу тыела.

36. Субсидия алучылар, Субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затлар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән тыш) үзләренә карата бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерү үткәрүгә, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгын бирергә тиеш.

37. Вәкаләтле орган Россия Федерациясе законнары нигезендә Субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерү үткәрә, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен бәяләү мөмкин булмаган очракта, урынга чыгып тикшерү үткәрелә. Субсидия алучы тикшерү өчен керү мөмкинлеген тәэмин итәргә, шулай ук күчмә тикшерү барышында субсидия бирү белән бәйле соратылган документларны тапшырырга тиеш.

38. Субсидия акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану өчен, шулай ук субсидия алу максатыннан тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә Субсидия алучыга йөкләнә.

39. Бюджет акчаларын файдалануны Вәкаләтле орган контрольдә тота.